КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 3 июль г.Казань № 538

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Лениногорск муниципаль районындагы «Исток-Башлангыч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе структурасын оптимальләштерү турында

Социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 1 гыйнварыннан «Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Лениногорск муниципаль районындагы «Исток-Башлангыч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең (алга таба – «Исток-Башлангыч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге) 28 койка-урынлы социаль-тернәкләндерү бүлеген бетерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

«Исток-Башлангыч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге тарафыннан бу учреждение структурасын оптимальләштерү чаралары үткәрелгәндә хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә тәэмин итәргә;

календарь көннәрдә исәпләнүче 30 көн эчендә «Исток-Башлангыч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә оператив идарә итү хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт милкәтенең кайбер төрләрен алга таба файдалану турындагы тәкъдимнәрне, әлеге мөлкәт исемлеген теркәп, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

«Исток-Башлангыч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге структурасын оптимальләштерүгә бәйле чараларны үткәрү чыгымнарын тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасының Хезмәт, эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча «Исток-Башлангыч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенең дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итүгә күздә тотылган чыгымнар өлешендә каралган акча кысаларында финанслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына календарь көннәрдә исәпләнүче 60 көн эчендә «Исток-Башлангыч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә элегрәк беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасының Хезмәт, эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан кертелгән мөлкәт исемлеге нигезендә тапшыруны законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә.

4. «Исток-Башлангыч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге структурасын оптимальләштерү чараларын үткәргәннән соң янга кала торган акча Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр күрсәтүчеләргә, халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә, чыгымнарны компенсацияләүгә (каплауга) субсидияләр рәвешендә гарантлар бирүгә җибәрелә.

5. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына, бу карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру максатларында, шулай ук аларны тәмамлаган вакытта, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә үзгәрешләр кертергә һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законына тиешле үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, бу карарның 2 нче һәм 3 нче пунктларында күрсәтелгән барлык чаралар тәмамланганнан соң календарь көннәрдә исәпләнүче 30 көн эчендә Татарстан Республикасының тиешле норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин